| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**09.07.2019** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1415** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 2010-2015 елларга һәм 2020 елга кадәрге перспективага энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

2009 елның 23 ноябрендәге «Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы №261-ФЗ Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 8 ноябрендәге №1941, 2013 елның 24 ноябрендәге №824, 2016 елның 24 ноябрендәге №3360 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 15 октябрендә №2154 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 2010-2015 елларга һәм 2020 елга кадәрге перспективага энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү муниципаль программасына үзгәрешләр кертергә.
2. ЯҮМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге җитәкчесе Д.С. Анисимовка әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.О.Котельниковка йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Кушымта

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына

____________________________

**Программаның паспортында «күләме һәм финанслау чыганаклары» пунктының 2 нче графасын түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга:** "Әлеге программаны гамәлгә ашыруга бәйле чараларны финанслау Зеленодольск муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр чикләрендә тиешле финанс елына гамәлгә ашырыла. Программаны тормышка ашыруга тотылган акчаларның күләме район бюджеты, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инфляция процесслары һәм икътисадый вәзгыять мөмкинлекләреннән чыгып төгәлләштерелергә һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин».